Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXVII-11**

Балык Бистәсе штп. 2022 елның 29 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында

Территориянең, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураның тотрыклы үсешен тәэмин итү, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 24, 25 маддәләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 маддәләре, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча 2022 елның 19 сентябрендә узган гавами тыңлауларның 1, 2, 3, 4 номерлы нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планын расларга.
2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Олы Кульга авылы, Мәктәп урамы, 11 йорт; Кече Кульга авылы, Первомайская урамы, 1 йорт; Дон-Урай авылы, Бакча тыкрыгы, 2 йорт; Олы Осиновка авылы, Кооперативная урамы, 1 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне  Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары  Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль
район Башлыгы
урынбасары                                                                                    Ф.Г. Әхмәтҗанова

**ОБЩЕСТВО С ОГРАНИЧЕННОЙ ОТВЕТСТВЕННОСТЬЮ «ГК-ГРУПП»**

КАДАСТРОВАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ

РФ, Республика Татарстан;
421001, г. Казань, ул. Четаева, д. 4; оф. 19
Тел. +7 (917) 231-59-81
ИНН/КПП 1659199710/165701001
ОГРН 1191690048615

Заказ бирүче: Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КУЛЬГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАНЫ

**Территориаль планлаштыру турында Нигезләмә**

Казан, 2022 ел

# ЭЧТӘЛЕК

**КЕРЕШ**.....ОШИБКА! ЗАКЛАДКА НЕ ОПРЕДЕЛЕНА.

**2. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КУЛЬГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ТУРЫНДА ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТЛАР** ..... 5

**3. ОЛЫ КУЛЬГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ОБЪЕКТЛАРЫН УРНАШТЫРУ ӨЧЕН ПЛАНЛАШТЫРЫЛА ТОРГАН БИЛГЕЛӘҮ ТӨРЛӘРЕ ҺӘМ ИСЕМНӘРЕ (АТАЛЫШЛАРЫ) ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТЛАР** ..... 5

3.1. ГОМУМИ ОЕШТЫРУ ЧАРАЛАРЫ ..... 6
3.2. СӘНӘГАТЬ ЖИТЕШТЕРҮЕН ҮСТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР ..... 6
3.3. АГРОСӘНӘГАТЬ КОМПЛЕКСЫН ҮСТЕРҮ ЧАРАЛАЫ ..... 8
3.4. УРМАН КОМПЛЕКСЫН ҮСТЕРҮ ЧАРАЛАРЫ ..... 8
3.5. ТОРАК ИНФРАСТРУКТУРАСЫН ҮСТЕРҮ ЧАРАЛАРЫ ..... 8
3.6. ХАЛЫККА ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ ӨЛКӘСЕН ҮСТЕРҮ ЧАРАЛАРЫ ..... 8
3.7. ЗИРАТЛАРНЫ КАРАП ТОТУ БУЕНЧА ЧАРАЛАР ..... 11
3.8. ТУРИСТИК-РЕКРЕАЦИОН ТЕРРИТОРИЯЛӘРНЕ ҮСТЕРҮ ЧАРАЛАРЫ ..... 11
3.9. ТРАНСПОРТ-КОММУНИКАЦИЯ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН ҮСТЕРҮ ЧАРАЛАРЫ ..... 13
3.10. ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ МОХИТНЕ САКЛАУ ЧАРАЛАРЫ ..... 14
3.11. ИНЖЕНЕРЛЫК ИНФРАСТРУКТУРАСЫН ҮСТЕРҮ ЧАРАЛАРЫ ..... 15
3.12. ТЕРРИТОРИЯНЕ ИНЖЕНЕРЛЫК ӘЗЕРЛӘҮНЕ ҮСТЕРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР ..... 16
3.13. ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ, ТАБИГЫЙ ҺӘМ ТЕХНОГЕН ХАРАКТЕРДАГЫ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘРНЕ КИСӘТҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР ..... 16

**4. ФУНКЦИОНАЛЬ ЗОНАЛАР ПАРАМЕТРЛАРЫ** ..... 17

# КЕРЕШ

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планы проектлаштыру йөкләмәсе нигезендә «ГК-Групп» ҖЧҖ тарафыннан эшләнде.

Генераль план проектын эшләүгә заказ бирүче – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты.

Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлеге генераль планы – шәһәр төзелеше стратегиясен, яшәү (тереклек итү) тирәлеген формалаштыру шартларын, җирлек территорияләрен үстерү юнәлешләрен һәм чикләрен, җирлек составындагы торак пунктлар чикләрен билгеләү һәм үзгәртү, территорияләрне функциональ зоналаштыру, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерү, тарихи-мәдәни мирас объектларын һәм махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклауга, экологик һәм санитария иминлегенә шәһәр төзелеше таләпләрен билгеләүче территориаль планлаштыру документы.

Генераль план аны тормышка ашыруның түбәндәге срокларына төбәп эшләнгән:

Генераль планны тормышка ашыру буенча беренчел чаралар билгеләнгән беренче чират – 2032 елга кадәр.

Генераль планның барлык төп проект чишелешләре планлаштырылган хисап срогы – 2042 елга кадәр.

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 23 маддәсе нигезендә Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планы үз эченә ала:

Текст һәм график материаллар составындараслана торган:

*Текст материаллары* – Территориаль планлаштыруның максатларын һәм бурычларын, территориаль планлаштыру чаралары исемлеген һәм генераль планны тормышка ашыру этаплары буенча аларны үтәү эзлеклелеген үз эченә алган территориаль планлаштыру турында Нигезләмә.

*График материаллар* территориаль планлаштыру картасын үз эченә ала.

Территориаль планлаштыру тәкъдимнәрен нигезләү һәм аңлату максатларында әзерләнә торган проектны нигезләү материаллары авыл җирлегенең генераль планын раслау процессын килештерү һәм тәэмин итү өчен, текст һәм график материаллар составында эшләнгән.

*Текст материаллары* җирлек территориясенең торышын, аны комплексны үстерү проблемаларын һәм юнәлешләрен анализлауны, территориаль һәм пространство-планлаштыру үсешен нигезләүне, территориаль планлаштыру чаралары исемлеген, аларны гамәлгә ашыру этапларын, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу хәвефлегенең төп факторлары исемлеген үз эченә ала.

*График материалларда* Генераль план нигезләмәләрен нигезләү схемалары бар.

Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планы проектын эшләгәндә түбәндәге материаллар файдаланылды:

– Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 21 февралендәге 134 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы (Министрлар Кабинетының 2022елның 15 мартындагы 235 номерлы карары редакциясендә);

– Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2022 елның 18 гыйнварындагы 07пи номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасы;

– Балык Бистәсе муниципаль районы администрациясе һәм аның составына керүче Олы Кульга авыл җирлеге тарафыннан тәкъдим ителгән рәсми мәгълүматлар.

## 2. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КУЛЬГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ТУРЫНДА ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТЛАР

Олы Кульга авыл җирлеге «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә төзелгән.

Хәзерге көндә Олы Кульга авыл җирлеге территориясендә торак пунктлар: Олы Кульга авылы (җирлекнең административ үзәге), Кече Кульга авылы, Дон-Урай авылы һәм Олы Осиновка авылы урнашкан.

Олы Кульга авыл җирлеге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының үзәк өлешендә урнашкан һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Уракчы, Күгәрчен, Троицкий Урай, Бәтке һәм Түбән Тегермәнлек авыл җирлекләре белән чиктәш.

Муниципаль берәмлекнең гомуми мәйданы 204142 га тәшкил итә, шул исәптән Олы Кульга авыл җирлеге мәйданы 8499 га һәм торак пунктлары мәйданы: Олы Кульга авылы-81,68 га; Кече Кульга авылы - 25,38 га; Дон-Урай авылы - 92,46 га; Олы Осиновка авылы - 61,43 га.

Олы Кульга авыл җирлегендә түбәндәге җәмәгать объектлары бар: мәктәп, балалар бакчасы, авыл мәдәният йорты, спорт корылмасы, Сабантуйны уздыру урыны, китапханә, почта бүлекчәсе, фельдшер-акушерлык пункты, ике дини оешма объекты һәм сәүдә объектлары.

Авыл җирлеге икътисадының әйдәп баручы тармагы булып авыл хуҗалыгы тора. Җирлек территориясендә «Бухаров» шәхси ярдәмче хуҗалыгы, «Әһлиев» КФХ, «Осиновка» КФХ, «Илдан» КФХ, «Кульга» ҖЧҖ, «Олы Кульга» АХК һәм терлекчелеккә һәм үсемлекчелеккә махсуслашкан фермалар урнашкан. Шулай ук умарталык бар.

Олы Кульга авыл җирлегенең Татарстан Республикасының башка җирлекләре һәм районнары белән транспорт элемтәсе хәзерге вакытта региональ яисә муниципальара һәм җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары аша гамәлгә ашырыла. Җирлек территориясе буйлап 16К-1355 М-7 «Волга» төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлы - Котлы Бөкәш - Балык Бистәсе, 16К-1361 М-7 «Волга» - Котлы Бөкәш - Балык Бистәсе – Олы Осиновка, шулай ук җирле әһәмияттәге автомобиль юллары уза.

## 3. ОЛЫ КУЛЬГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ОБЪЕКТЛАРЫН УРНАШТЫРУ ӨЧЕН ПЛАНЛАШТЫРЫЛА ТОРГАН БИЛГЕЛӘҮ ТӨРЛӘРЕ ҺӘМ ИСЕМНӘРЕ (АТАЛЫШЛАРЫ) ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТЛАР

### 3.1. Гомуми оештыру чаралары

Олы Кульга авыл җирлегенең үсеш юнәлешен билгеләгәндә Татарстан Республикасының, Балык Бистәсе муниципаль районының, Олы Кульга авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш программалары, төбәк һәм федераль тармак программалары исәпкә алынды.

2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе» расланды. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 25 сентябрендәге 707нче карары белән «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен тормышка ашыру чаралары планы» расланды. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 20 июнендәге 503 номерлы карары белән «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен тормышка ашыру чаралары планы»на үзгәрешләр кертү расланды.

Балык Бистәсе муниципаль районы расланган Стратегия кысаларында түбәндәге проектларны тормышка ашыру территориясе булып тора: «Рус этнографик авылы», «Балык Бистәсе районы тарихы» (Татарстанның энҗе муенсасын киңәйтү), «Балык Бистәсе крае», «Балык Бистәсе районы халыкларының дине һәм традицияләре», «Уңайлы мохит».

### 3.2. Сәнәгать җитештерүен үстерү буенча чаралар

Сәнәгать җитештерүе өлкәсендәге чаралар Олы Кульга авыл җирлегенең көньяк-көнбатышында «Гаприн» биопротеин җитештерү объектын төзүне үз эченә ала. Гомуми мәйданы 25 га.

Таблица 3.2.1

Олы Кульга авыл җирлеге территориясендә сәнәгать җитештерүен үстерү чаралары исемлеге

| № п/п | Җирлек составына керә торган торак пункт исеме | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлчәү берәмлеге | Егәрлек | | Тормышка ашыру сроклары | | Чаралар чыганагы (документның аталышы) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Гамәлдәге | Өстәмә | Беренче чират ( 2032 елга кадәр) | Хисап срогы (2032-2042 еллар) | |
| ҖИРЛЕ (ҖИРЛЕК) ӘҺӘМИЯТЕНДӘГЕ ЧАРАЛАР | | | | | | | | | |
| 1 | Дон-Урай авылының көньяк-көнбатышынгда | «Гаприн» биопротеины җитештерү | Тцзелеш | га | 0 | 25 | + | - | Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планы |

### 3.3. Агросәнәгать комплексын үстерү чаралары

Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планы белән хисап срогына кадәр агросәнәгать производствосын үстерү чаралары каралмаган.

### 3.4. Урман комплексын үстерү чаралары

Урман хуҗалыгы өлкәсендәге чаралар урманнарны яңадан торгызу, янгыннан, пычранудан (шул исәптән радиоактив матдәләрдән) һәм башка тискәре йогынтыдан саклау чараларын, шулай ук зарарлы организмнардан саклау, шәһәрләр һәм торак пунктларның яшел зоналары мәйданнарын саклау һәм арттыру, шулай ук урман фонды һәм урман хуҗалыгы мәнфәгатьләренә кагылышлы башка өлкәләрнең эшчәнлеген үз эченә ала. Татарстан Республикасының барлык урманнары Россия Федерациясе милке булганлыктан, барлык чаралар да федераль әһәмияткә ия һәм федераль дәрәҗәдә контрольдә тотылырга тиеш.

Олы Кульга авыл җирлегенең генераль планы, Балык Бистәсе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасы һәм башка программалар, хисап срогына кадәр булган документлар белән урман һәм урман сәнәгате комплексын үстерү буенча башка чаралар каралмый.

### 3.5. Торак инфраструктурасын үстерү чаралары

Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планы белән хисап срогына кадәр торак инфраструктурасын үстерү чаралары каралмаган.

### 3.6. Халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсен үстерү чаралары

Олы Кульга авыл җирлегенең генераль планының төп максатларыннан берсе – фаразланган сыйфатламаларны һәм социаль нормаларны исәпкә алып, җирлек халкының хезмәт күрсәтү учреждениеләрендәге ихтыяҗларын канәгатьләндерү, шулай ук барлык халык өчен хезмәт күрсәтү объектларының тигез шартларын тәэмин итү.

Олы Кульга авыл җирлегендә хезмәт күрсәтү объектларын урнаштыру чаралары Балык Бистәсе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасын, 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Кульга авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеше Стратегиясен исәпкә алып билгеләнде.

<u>Мәгариф оешмалары</u>

*Балаларга өстәмә белем бирүне оештыру.* Җирлек территориясендә өстәмә белем бирү оешмасы булмау сәбәпле, өстәмә белем бирү оешмаларына ихтыяҗ ачыкланды.

Генераль план нигезендә, беренче чиратта, 7 урынлы ябылган балалар бакчасы урынына балаларга өстәмә белем бирү оешмасын урнаштыру тәкъдим ителә.

Физик культура һәм спорт объектлары

Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планы белән гомуми мәйданы 1565 кв. м булган яссылык корылмасының 1 объектын төзү тәкъдим ителә.

Сәүдә объектлары

Сәүдә мәйданының кв. метры буенча нормативларга туры килмәү сәбәпле, Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планы тарафыннан 153 кв.м мәйданлы кибет төзү каралган.

Таблица 3.6.1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Кульга авыл җирлеге халкына социаль һәм мәдәни-көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларын үстерү чаралары исемлеге

| № п/п | Җирлек составына керә торган торак пункт исеме | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлчәү берәмлеге | Егәрлек | | Тормышка ашыру сроклары | | Чара чыганагы (документның аталышы)) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Гамәл дәге | Өстәмә | Беренче чират | Хисап срогы | |
| Җирле (район) әһәмияттәге чаралар | | | | | | | | | |
| 1 | Олы Кульга авылы | Өстәмә белем биру оешмасы | Яңа төзелеш | урын | 0 | 7 | + | + | Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планы |
| 2 | Олы Кульга авылы | Яссылык корылмасы | Яңа төзелеш | объект | 1 | 1 | + | + | Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планы |
| 3 | Дон-Урай авылы | Кибет | Яңа төзелеш | кв.м. сәүдә мәйданы | 22 | 153 | + | + | Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планы |

## 3.7. Зиратларны карап тоту буенча чаралар

1000 кешегә 0,24 гектар норматив булган очракта, Олы Кульга авыл җирлегенең традицион җирләү белән булган зиратларга ихтыяҗы - 0,14 га.

Гамәлдәге зиратларның ирекле территорияләре халыкның традицион җирләү белән бәйле каберлекләргә ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерәчәк.

## 3.8. Туристлык-рекреация территорияләрен үстерү чаралары

Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планында рекреация территорияләрен үстерү җирле халыкның ялы зонасы буларак яшел утыртмалар системасын оештыру чараларын күздә тота.

Кешеләр ялы өчен уңайлы мөмкинлекләр тудыру, авыл торак пунктының йөзен яхшырту өчен кирәкле яшел утыртмалар системасын оештыру чаралары комплексы ике төп этапны күздә тота: гомуми файдаланудагы яшелләндерүне оештыру һәм чикләнгән файдалануны яшелләндерүне оештыру.

Гомуми файдаланудагы яшел утыртмаларны оештыру чаралары – административ һәм җәмәгать биналары янындагы скверлар, көндәлек хезмәт күрсәтү үзәкләре булдыру, төп урамда бульвар төзү, урамнарны яшелләндерү, чәчәклекләр һәм газоннар ясау.

Чикләнгән файдаланудагы яшел утыртмаларны оештыру чаралары – мәгариф һәм тәрбия объектлары территорияләрен яшелләндерү һәм социаль һәм мәдәни-көнкүреш хезмәтләре күрсәтү объектлары (өй арты (өйтүр) бакчалары төзү, җиләк-җимеш һәм декоратив агачлар, куаклар утырту, чәчәк түтәлләре урнаштыру).

Шәһәр төзелешен проектлауның региональ нормативларына ярашлы рәвештә, торак зонасында күпфатирлы йортлар төзелгән микрорайонның (кварталның) яшелләндерелгән территориясе мәйданы (гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмалары кишәрлекләрен исәпкә алмыйча) квартал территориясенең кимендә 25 процентын тәшкил итәргә тиеш. Гомуми белем бирү оешмалары территорияләрен яшелләндерүне аларның мәйданы кимендә 50 % исәбеннән күз алдында тота. Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары территорияләрен яшелләндерү төзелештән ирекле территориянең кимендә 50 процентын тәшкил итәргә тиеш.

Таблица 3.8.1

Олы Кульга авыл җирлегендә туристлык-рекреация территорияләрен үстерү чаралары исемлеге

| № п/п | Җирлек составына керә торган торак пункт исеме | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлчәү берәмлеге | Егәрлек | | Тормышка ашыру сроклары | | Чара чыганагы (документның аталышы)) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Гамәлдәге | Өстәмә | Беренче чират ( 2032 елга кадәр) | Хисап срогы (2032-2042 еллар) | |
| ҖИРЛЕ (ҖИРЛЕК) ӘҺӘМИЯТЕНДӘГЕ ЧАРАЛАР | | | | | | | | | |
| 1 | Олы Кульга авыл җирлеге | Гомуми файдаланудагы яшелләндерү | Яшел утыртмалар системасын оештыру | - | - | - | + | + | Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планы |
| 2 | Олы Кульга авыл җирлеге | Объектлар территорияләрен яшелләндерү | Яшел утыртмалар системасын оештыру | - | - | - | + | + | Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планы |

## 3.9. Транспорт-коммуникация инфраструктурасын үстерү чаралары

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Кульга авыл җирлегенең генераль планы составында Олы Кульга авыл җирлегенең "Транспорт-коммуникация инфраструктурасын үстерү" бүлегенең төп максаты – җирлек икътисадының нәтиҗәлелеген һәм көндәшлеккә сәләтлелеген арттырып, кирәкле техник халәтне, үткәрү сәләтен, юл челтәренең куркынычсызлыгын һәм тыгызлыгын тәэмин итеп, халык ихтыяҗы буенча автомобиль юлларын үстерү.

<u>Автомобиль юлларын үстерү</u>

Региональ яисә муниципальара һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын үстерү юнәлешләре Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасында һәм Балык Бистәсе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасында билгеләнде.

Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы һәм Балык Бистәсе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасы буенча Олы Кульга авыл җирлеге территориясендә яңа юллар төзү күздә тотылмый.

<u>Урам - юл челтәрен үстерү</u>

Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планы белән урам-юл челтәрен үстерү буенча чараларның хисап срогына кадәр тәкъдим ителми.

## 3.10. Әйләнә-тирә мохитне саклау чаралары

Таблица 3.10.1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Кульга авыл җирлеге территориясендә тормышка ашыруга тәкъдим ителә торган әйләнә-тирә мохитне саклау чаралары исемлеге

| № п/п | Объектның исеме (аталышы) | Сара төре | Тормышка ашыру сроклары | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Беренче чират | Хисап чоры |
| 2 | объектларның санитар-саклау зоналарын яшелләндерү | оештыру чарасы | + | |
| 3 | әйләнә-тирә мохит торышына экологик мониторинг | оештыру чарасы | + | + |
| 4 | территорияне санитар чистарту | оештыру чарасы | + | + |
| 5 | су басудан кисәтү чаралары | оештыру чарасы | + | + |
| 6 | карстка каршы чаралар үткәрү | оештыру чарасы | + | + |
| 7 | чокырларны төзекләндерү һәм яшелләндерү | оештыру чарасы | + | |
| 8 | төзелеш процессында бозылган җирләрне рекультивацияләү | оештыру чарасы | + | |
| 9 | гамәлдә булмаган объектлар территорияләрен рекультивацияләү һәм яшелләндерү | оештыру чарасы | + | |
| 10 | җирләрне инвентаризацияләү һәм агрохимик тикшерү | оештыру чарасы | + | + |
| 11 | тавыштан саклаучыэкраннар урнаштыру | оештыру чарасы | + | |
| 12 | саклаучы яшелләндерү утырту | оештыру чарасы | + | |

## 3.11. Инженерлык инфраструктурасын үстерү чаралары

Таблица 3.11.1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Кульга авыл җирлеге составына керүче торак пунктлар территориясендә калдыклар белән эш итү системасын үстерү чаралары исемлеге

| № п/п | Урнашу урыны | Объектның аталышы | Чараның төре | Үлчәү берәмлеге | Егәрлек | | Тормышка ашыру сроклары | | Чара чыганагы (документның аталышы)) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Гамәлдә ге | Өстәмә | Беренче чират | Хисап срогы | |
| Җирле (район) әһәмияттәге чаралар | | | | | | | | | |
| 1 | Авыл җирлеге территориясе | Контейнерлар | Оештыру | данә | 0 | 23 | + | - | Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планы |
| 2 | Авыл җирлеге территориясе | Контейнерлар | Оештыру | данә | 0 | 25 | - | + | Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планы |

## 3.12Территорияне инженерлык әзерләүне үстерү буенча чаралар

Таблица 3.12.1

| № п/п | Урнашу урыны | Объектның исеме (аталышы) | Чараның исеме | Чараның төре | Үлчәү берәм леге | Егәрлек | | Тормышка ашыру сроклары | | Чараның чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | гамәл дәге | яңа (өстә мә) | беренче чират | хисап срогы | |
| Җирле әһәмияттәге чаралар | | | | | | | | | | |
| 1 | Авыл жирлеге территориясе | - | Куркыныч табигый процесслар күренешләренә мониторинг | Оештыру | | | | + | + | Олы Кульга авыл жирлегенең Генераль планы |
| 2 | Авыл жирлеге территориясе | - | Район территориясен куркыныч табигый процесслардан саклау буенча чаралар эшләү | Оештыру | | | | + | + | Олы Кульга авыл жирлегенең Генераль планы |

## 3.13. Гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү буенча чаралар

Таблица 3.13.1

| № п/п | Урнашу урыны | Объектның исеме (аталышы) | Чараның исеме | Чараның төре | Үлчәү берәмлеге | Егәрлек | Тормышка ашыру сроклары | | Чараның чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | беренче чират | хисап чоры | |
| 1 | Авыл җирлеге территориясе | Торак пунктларда хәбәр итү системасы | Хәбәр итү системаларын урнаштыру | Төзелеш | данә | 4 | + | - | Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планы |
| 2 | Дон-Урай авылы | Янгынга каршы гидрант | Гидротехник корылманы урнаштыру | Төзелеш | данә | 1 | + | - | Олы Кульга авыл җирлегенең Генераль планы |

# 4. ФУНКЦИОНАЛЬ ЗОНАЛАР ПАРАМЕТРЛАРЫ

Таблица 4.1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлеге Генераль планы проектында кулланыла торган функциональ зоналар параметрлары

| № п/п | Функциональ зона иceме (аталышы) | Функциональ зонаның билгеләнешен тасвирлау | Функциональ зона параметрлары | Җир кишәрлекләрен функциональ зонада рөхсәт ителгән файдалану төрләренең кодлары[1] | Урнаштыру өчен планлаштырыла торган объектлар[2] |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Индивидуаль торак йортлар салу зонасы | Торак йортны урнаштыру (җир өсте катлары саны кимендә өч, биеклеге егерме метрдан артмаган аерым бина, ул гражданнар тарафыннан көнкүреш һәм башка ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен билгеләнгән ярдәмче файдаланудагы бүлмәләрдән һәм урыннардан тора, күчемсез мөлкәтнең мөстәкыйль объектларына бүлү өчен билгеләнмәгән мондый бинада аларның яшәве белән бәйле); авыл хуҗалыгы культураларын үстерү; индивидуаль гаражлар һәм хуҗалык корылмалары урнаштыру | Төп төзелеш катларының иң чик саны: 3 ( мансардны да кертеп); Төзелеш коэффициенты: 0,2-0,3 | 2.1; 2.2; 2.3; 3.4.1; 3.5.1; 3.8.1; 3.10.1; 4.4; 5.1.3; 9.3; 11.1, 11.2; 11.3; 12.0.1; 12.0.2 | - |
| 2 | Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона | Административ учреждениеләр; көнкүреш хезмәтләре күрсәтүне тәэмин итүче объектлар; кунакханә хезмәте күрсәтү объектлары; ветеринария хезмәтләре күрсәтүне тәэмин итүче объектлар; социаль хезмәт күрсәтү объектлары; сәүдә объектлары, базарлар - җәмәгать туклануы объектлары; эшкуарлык һәм эшлекле идарә объектлары; банк һәм иминият хезмәтләре күрсәтүче учреждениеләр; эчке хокук тәртибен тәэмин итү өчен кирәкле объектлар; | Төп төзелеш катларының иң чик саны: 5 (мансардны да кертеп); Төп төзелешнең иң чик биеклеге: 20 м; Төзелеш коэффициенты: 1 | 2.7; 3.1.2; 3.2.2; 3.2.3; 3.2.4; 3.3; 3.4.1; 3.4.2; 3.5.1; 3.5.2; 3.6.1; 3.7.1; 3.7.2; 3.8.1; 3.8.2; 3.9.2; 3.10.1; 4.1; 4.4; 4.5; 4.6; 4.7; 4.8.1; 5.1.1; 5.1.2; 5.1.3; 9.3; 11.1, 11.2; 11.3; 12.0.1; 12.0.2 | Кибет |

| № п/п | Функциональ зона исеме (аталышы) | Функциональ зонаның билгеләнешен тасвирлау | Функциональ зона параметрлары | Җир кишәрлекләрен функциональ зонада рөхсәт ителгән файдалану төрләренең кодлары[1] | Урнаштыру өчен планлаштырыла торган объектлар [2] |
|---|---|---|---|---|---|
| 3 | Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы | Медицина хезмәте күрсәтү объектлары; дини файдаланудагы биналар һәм корылмалар; мәгариф һәм мәгърифәт объектлары; мәктәпкәчә, башлангыч һәм урта гомуми белем бирү объектлары, белем бирү түгәрәкләре; мәдәният объектлары, мәдәни-ял итү эшчәнлеге; көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары; күңел ачу чараларын оештыру өчен билгеләнгән объектлар; спорт объектлары; күргәзмә-ярминкә эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектлар; | Төп төзелеш катларының иң чик саны: 5 (включая мансардный); 5 (мансардны да кертеп); Төп төзелешнең иң чик биеклеге: 20 м; Төзелеш коэффициенты: 0,8 | 3.2.1; 3.2.2; 3.2.3; 3.2.4; 3.3; 3.4.1; 3.4.2; 3.4.3; 3.5.1; 3.5.2; 3.6.1; 3.7.1; 3.7.2; 3.8.1; 3.8.2; 3.9.2; 3.10.1; 4.1; 4.5; 4.6; 4.7; 5.1.2; 5.1.3; 11.1, 11.2; 11.3; 12.0.1; 12.0.2 | - |
| 4 | Инженерлык инфраструктурасы зонасы | Торак пунктларны электр, газ, җылылык, су белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәс субүлү объектлары; антенна-мачта корылмалары, элемтә объектлары; гидротехник корылмалар; | Билгеләнми | 2.7.1; 3.1.2; 3.9.1; 6.7; 11.1, 11.2; 11.3; 12.0.1; 12.0.2 | - |
| 6 | Авыл хуҗалыгы предприятиеләренең җитештерү зонасы | IV һәм V класслы хәтәрлектәге авыл хуҗалыгы җитештерүе объектлары; санитар-яклау зонасы проектын җитештергәндә һәм эшләгәндә алдынгы технологик карарлардан файдалану шартларында, башка класслы хәтәрлектәге авыл хуҗалыгы җитештерүе объектлары; авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм тирән эшкәртү өчен кулланыла торган биналарны, корылмаларны урнаштыру; авыл хуҗалыгы техникасы өчен машина-транспорт һәм ремонт станцияләрен, ангарларны һәм гаражларны, суэтем башняларын, трансформатор станцияләрен һәм авыл хуҗалыгын алып бару өчен кулланыла торган башка техник җиһазларны урнаштыру; | Төзелеш коэффициенты: 0,8 | 1.3; 1.5; 1.8; 1.9; 1.10; 1.11; 1.12; 1.13; 1.14; 1.15; 1.17; 1.18; 2.7.1; 3.9.1; 3.10.1; 4.4; 4.6; 4.9.1.1; 4.9.1.3; 6.9; 6.9.1; 6.12; 11.1, 11.2; 11.3; 12.0.1; 12.0.2 | - |

| № п/п | Функциональ зона исеме (аталышы) | Функциональ зонаның билгеләнешен тасвирлау | Функциональ зона параметрлары | Җир кишәрлекләрен функциональ зонада рөхсәт ителгән файдалану төрләренең кодлары[1] | Урнаштыру өчен планлаштырыла торган объектлар [2] |
|---|---|---|---|---|---|
| 7 | Урманнар зонасы | Саклаучы урманнарны карау; саклау урманнарында рөхсәт ителгән башка хуҗалык эшчәнлеге, тыюлыкларда табигать ресурсларыннан файдалану режимын үтәү, аеруча кыйммәтле булган җирләрнең үзлекләрен саклау; агач материалын һәм агач булмаган урман ресурсларын әзерләү, беренчел эшкәртү һәм чыгару эшчәнлеге; урманнарны саклау һәм торгызу; | Билгеләнми | Билгеләнми | - |
| 8 | Зиратлар зонасы | Җирләү урыннарын урнаштыру | Билгеләнми | 3.1.1; 3.9.1; 11.1, 11.2; 11.3; 12.0.1; 12.0.2; 12.1 | - |
| 9 | Махсус билгеләнештәге яшелләндерелгән территорияләр зонасы | Торак пунктларда үзлегеннән тишелгән яшел утыртмалар; гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр; урам-юл челтәре | Билгеләнми | 12.0.1; 12.0.2; 12.3 | - |
| 10 | Гомуми файдаланудагы территорияләрне яшелләндерү зонасы | Мәдәният һәм ял паркларын урнаштыру | Билгеләнми | 3.6.2 | - |
| 11 | Акваторияләр зонасы | Өске су объектлары; | Билгеләнми | Билгеләнми | - |
| 12 | Авыл хуҗалыгы җирләре зонасы | - авыл хуҗалыгы культуралары җитештерүгә бәйле авыл хуҗалыгы җирләрендә хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыру;<br>авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү;<br>- кыр юллары; | Билгеләнми | Билгеләнми | - |
|  | Башка зоналар | гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләре;<br>-урам-юл челтәре | Билгеләнми | 12.0.1; 12.0.2; 12.3 | - |